**Задания заключительного тура Акмуллинской олимпиады по татарскому языку и литературе для учащихся 10-11 классов, студентов СПО**

1. Буш урыннарга исемнәрнең данә исәбен белдергән сүзләрне куегыз (5 б):

1 капчык ...он, бодай
икмәк ...телеме
1 уч ...җиләк
Салам, чүп ... өеме
10 баш ...мал
1 кочак ...утын
1 тотам ...үлән
арыш .... көлтәсе
2 кап ...шырпы
чәчәк ...бәйләме

2. Саннар артына яшеренгән мәкальне табып языгыз (10 б).

1, 12 38, 13, 23, 34, 21, 23, 13, 1, 16, 6, 1 12, 18, 14, 6, 34, 10 13, 25, 7, 36, 15, 11.

Ай яктыртканда йолдыз күренми.

3. Канатлы сүзләрне рус теленә тәрҗемә итегез: (12 б)

Ахиллес үкчәсе Ахиллесова пята,
Шөкатьсез үрдәк баласы Гадкий утенок,
Дары мичкәсендә дары бар әле есть еще порох в пороховницах,
Очкыннан ялкын кабына из искры возгорится пламя,
Крокодил күз яше Крокодиловы слезы,
Аю хезмәте күрсәтү Оказывать медвежью услугу.

4. Түбәндәге формулаларга туры килгән сандхи очракларына 1-әр мисал китерегез (3+3=6):

е + ә = ә иле + әрем = илләрем
ы+у=у сары + ут = сарут

5. Дөрес җавапны билгеләгез (4 б.):

*Бергә алар язгы урман һавасы суладылар, яр буенда саргылт тал ПИПИЛӘРЕ өзделәр* (Н.Фәттах). Җөмләдә аерып бирелгән сүз:

- профессионализм
- архаизм
- диалектизм
- неологизм

Алар билгеле бер формага буйсынган булалар. Аларда мәҗбүри җөмлә калыплары, сүзтезмәләр, тәгъбирләр кулланыла, алардан зур төгәллек сорала.

- матур әдәбият әсәрләре
- рәсми эш кәгазьләре
- публицистик әсәрләр
- драма әсәрләре

Бирелгән кереш сүзләр нинди мәгънә белдерәләр?
*ихтимал, күрәсең, бәлки, ахрысы, ахры*

– билгесезлекне
– үтенүне
– сөйләүченең төрле тойгысын
– фикер эзлеклелеген

Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" әсәренең тулы текстын беренче булып кулъязмада әзерләгән әдип:

– С.Сараи
– Г.Утыз Имәни
– Й.Баласагунлы
– Колшәриф

6. Дөрес җавапларны билгеләгез: (3 б)

1. Әсәрләрнең жанрын языгыз:

"Сөннәтче бабай" хикәя.
"Беренче театр" комедия.
"Сак-Сок" бәет

7. Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасында автор югары күтәргән сыйфатлар (1 сыйфат – 1 б. =5 б.).

Дуслык
Шаласлык
Тормыш сөючәнлек
Кешелеклек.
Үзәтлек

8. М. Акмулла "Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән" дип язган. Автор турында 5 факт яз (10 б.)

Башкортстанның Миякә районы Туксанбай авылында туган,
Акмулла - туры сүзне дигәнне кушамат тагыла,
Чын исеме - Камалетдинов Миртахетдин Камалетдинович,
татар, башкорт, казах халыкларының уртак шагыйре,
үлгәннән соң тагын ике китабы чыга.

9. Җәяләрне ачып, дөрес языгыз (5 б).

(1)Сулар ага... (2) Җир (йөзендә) йөзендә сулар бер (туктаусыз) бертуктаусыз агалар (да) агалар. (3)Җәй агалар, яз агалар, көз агалар... (4)Агым сулар кешеләрнең чир (чорларын) чир-чорларын, кайгыларын, языкларын алалар (да) алалар да еракларга, упкыннарга, чоңгылларга ыргыталар. (5)Агым сулар, җир (өстенең) җир өстенең чүп (чарларын) чүп-чарларын юып алып, үзләрендә юк итәләр. (6)Шулай ел (да) елда җир яңара, җир яшәрә.

(7)Җир яңара, җир яшәрә... (8)Өзелмичә, туктамыйча, бөек Чулман кебек, Әтил кебек, көн (төн) көн-төн җирдә тормыш ага.

(9)Яз килде, яз!... 10)Киң Чулманга – кояш белән, ай (йолдызлар) ай, йолдызлар белән яшьтәш Чулманга ашыгып төрле[ ](яктан) сулар ага...(Н. Фәттах).

10. Бирелгән өзек нинди әсәрдән? (2 б.) Итил суы ака торур.

11. Түбәндәге тел күренешләре булган җөмлә номерларын куярга (5 б):

1) ялгызлык исемнәре
2) парлы сүзләр
3) гөнаһ сүзенә синоним
4) юклык формасындагы фигыль
5) вакыт мәгънәсен белдергән исем

| 1) | 2) | 3) | 4) | 5) |
|---|---|---|---|---|
| 8,10, | 3,5,8. | 4 | 8 | 3,6,8. |

12. 5нче җөмләдә хәбәрнең төре (3 б.) Кушма хәбәр

13. Өзекне дәвам итеп эссе языгыз. Күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш (30 б.)

Карларны, салкыннарны, бураннарны белән кыш үтә. Калын бозларны ватып, ярларыннан ташып, елгалар ага. Язгы кояшның кайнар күз карашлары астында сыңгып карлар эри. Кошлар кайта, үз парларын эзләп, өзелеп-өзелеп сайрый алар. Шундый рәхәт! Саф, сафлык белән тулы изге һава. Агачларның яшь-яшел яфракларыннан да яңа гына күзен ачкан умырзая чәчәкләреннән дә, ылыннан-ылынга, гөлдән-гөлгә елкергән чык тамчыларыннан да сафлык бөркелеп тора. Гаҗәп, су ул үзе сафлык. Ә яшьлек – кеше гомеренең язы. Шулай булгач, тузларда тузанланган, ярсу агымнарда узып торган яшьлек тә саф ич.

Тормыш бозларын эретерлек, кыя-тауларны җимерерлек көче дә, шиңгән гөлләрне терелтерлек назы да, ул сафлыкка төренгән хыялый, изге яшьлек.

Соклангыч хуш исле чәчәктәй яшьлекне корыту сугамы? Кешеләр, утлы-яфракланда кагып торган, чын сулыштай саф мәхәббәтне заманның кайнар сулышы киптерәме? Нишләп хәзер гашыйклар һаман сатыла, караңгы почмаклар эзлиләр? Соклангыч тугрылыклык

чәчәкләренең матурлыгын да күрми, таптап үтәләр. Нишләп аңламыйлар, чәчәкләрне туган җимешләрен таптап бетерә алар. Күз ачып йомганчы үтә торган язны башка беркайчан да кайтмаячак җимешләрен кабат кайтып бирәләрме? Алмасулардай ашыкмый үтәр гомер юллары, кызыйлары, сизми дә калырлар, яңгырлары ява башлар, көз җитәр. Кырау төшәр, җирне генә кыш килер. Үткән юлларына борылып карарлар. Тик җәелеп төшкән сары яфраклардан башка нәрсә күрерләр? Эзләр алар, ләкин сагынырлык сафлыкка торерлек җимешләре юклыгын аңлагач, йөрәкләре әрнер, күңелләре сыкрар.

Әйе, Уйламан төрле ягтан аккан сулар белән баеган, үңгән кебек, кеше дә мин-минлеге белән тәҗрибә туплый, акыл җыябыз шул.